КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 октябрь г.Казань № 942

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы, 2006 ел, 19 июнь, 312 нче, 2010 ел, 31 май, 419 нчы, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы, 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы, 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы, 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы, 2013 ел, 19 март, 185 нче, 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче, 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче, 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы, 2016 ел, 19 март, 150 нче, 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы, 2017 ел, 3 февраль, 58 нче, 2017 ел, 20 апрель, 232 нче, 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче, 2018 ел, 22 март, 161 нче, 2018 ел, 5 июнь, 430 нчы, 2018 ел, 17 декабрь, 1155 нче, 2019 ел, 16 март, 185 нче, 2019 ел, 22 июль, 613 нче, 2020 ел, 11 февраль, 99 нчы, 2020 ел, 11 июль, 575 нче, 2020 ел, 19 август, 710 нчы, 2021 ел, 21 гыйнвар, 19 нчы, 2021 ел, 18 июнь, 476 нчы, 2021 ел, 6 декабрь, 1168 нче, 2022 ел, 22 апрель, 389 нчы, 2022 ел, 1 июнь, 511 нче, 2022 ел, 18 август, 852 нче, 2022 ел, 2 сентябрь, 946 нчы, 2022 ел, 1 ноябрь, 1165 нче, 2022 ел, 5 декабрь, 1288 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1485 нче, 2023 ел, 12 апрель, 451 нче, 2023 ел, 9 июнь, 704 нче, 2023 ел, 2 август, 936 нчы, 2023 ел, 31 август, 1058 нче, 2024 ел, 20 май, 339 нчы, 2024 ел, 24 июнь, 453 нче, 2024 ел, 4 июль, 500 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «2 470,007» саннарын «2 484,729» саннарына алмаштырырга;

3 пунктта «дүрт урынбасар» сүзләреннән соң «, шул исәптән бер беренче урынбасар» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

3.3 пунктның җитмешенче абзацында «транспорт инфраструктурасы объектларында» сүзләрен «транспорт инфраструктурасы объектлары һәм транспорт чаралары» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктның икенче абзацында «урынбасарлары» сүзеннән соң «, шул исәптән бер беренче урынбасар» сүзләрен өстәргә;

5.2 пунктның өченче абзацында «Коллегия саны һәм составы раслана» сүзләрен «Коллегия составы раслана» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 10 октябрь, 1284 нче, 2023 ел, 23 ноябрь, 1499 нчы, 2024 ел, 26 гыйнвар, 34 нче, 2024 ел, 18 март, 155 нче, 2024 ел, 10 май, 316 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимияте органының үзәк аппараты структурасы стандартына, 7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«7. Татарстан Республикасы министрлыклары һәм дәүләт комитетлары җитәкчеләренең бердән артык ярдәмчесе була алмый, үзәк аппарат структурасында икедән артык ярдәмче була алмаган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгыннан тыш. Башка республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре ярдәмчегә ия була алмый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 октябрь, 942 нче
карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы структурасы

